# «Яңарыш» фонды





*Безгә сезнең белән тарихи миссия тапшырылды – халкыбызда булганны сакларга, аны яңадан торгызырга һәм киләчәк буынга җиткерергә. Болгар һәм Свияжск шәһәрләренең тарихи күренешен аякка бастыру дәүләт, бизнес, дини оешмалар һәм җәмгатьчелекнең иң зур бердәм проекты булачак. Аның исеме – «Яңарыш».*





2008 елда кабул ителгән Татарстан Республикасы дәүләт мәдәни сәясәте концепциясендә бик мөһим приоритетлар искә алына: «Татарстан территориясендә яшәүче милләт вәкилләренең интеллектуаль, мәдәни һәм рухи-әхлакый мирасын саклау, краеведение һәм музей эшен үстерү, алар тарихи һәм үзара мәдәни йогынты һәм бәйләнешләре турындагы белемнәрне популярлаштыру».

*«Болгар һәм Свияжск кебек танылган тарихи-архитектур ядкәрләрне аякка бастыру проекты хәзерге һәм киләчәк буын өчен ифрат мөһим. Бер җирдә, Идел буенда ике диннең – ислам һәм православие – тату яшәвенең үрнәге күрсәтеләчәк».*

*М. Шәймиев*









Милләтнең рухи күтәрелеше, төрле конфессияләр бердәмлеге һәм культуралар диалогын ныгыту өлкәсендәге күпьеллык актив эшчәнлеген дәвам итеп Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев 2010 елда «Яңарыш» фондын оештыра. Фонд эшчәнлегенең мөһим башламы булып «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» уникаль проектын тормышка ашыру тора.

Борынгы шәһәрләрне торгызу – мөселман һәм православие дине һәм культуралары үзәге, Россия һәм Татарстанның күпмилләтле халкының рухи яңарышында бик зур этап булып торачак. Архитетур, тарихи ядкәрләр, борынгы гадәтләр символлары бүген регионның мөһим алгарыш ресурслары булып тора, турист һәм инвесторларны җәлеп итә.

Татарстанның мәдәни объектларының уникальлеге Казан Кремле тарихи-мәдәният ансамбленең 2000 елда ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасы исемлегенә кертелү белән билгеләнә. Чиратта Болгар дәүләт тарихи-архитектур музей-тыюлыгы һәм Свияжск тарихи-архитектур һәм табигый-ландшафт комплексы тора (киләчәктә – федераль әһәмияте булган Дәүләт тарихи-архитектур һәм художество музей-тыюлыгы Свияжск утрау-шәһәре).





«Яңарыш» фонды алдында чын мәгънәсендә революцион вазыйфа тора: агымдагы берничә ел эчендә, системалы һәм масштаблы фәнни тикшеренү белән беррәттән, борынгы шәһәрләрне торгызу, реставрацияләү генә түгел, ә бәлки туристлык һәм сәяхәт маршрутлары да ачу. Болгар һәм Свияжскида сокландыргыч борынгылыкны, кабатланмас тарихи рухны саклап, алдынгы архитетур һәм техник фикер белән баетылган заманча туристлык мәркәзләре барлыкка китерергә кирәк.

Проект үз эченә сәяхәт итүчеләргә уңай шартлар хасил итәчәк, шул ук вакытта заповедникларның ландшафтын бозмаячак инфраструктура объектларын төзүне кертә (причаллар, элемтәләр, кунакханәләр). Борынгы ядкәрләргә саклык белән карауны заповедниклар территориясендә барган археологик тикшеренүләр тәэмин итәчәк.





# Борынгы
# Болгар







*«Болгар – Идел ярының иң матур җирендә, туристлык маршрутлары кисешкән урында урнашкан борынгы мәдәният ядкәре. Нәкъ шушында, Киев Русенең чукындыруына берничә дистә ел кала, 922 елда ислам дәүләт дине буларак кабул ителә».*

Тарихи мәгълүматлар Урта Идел болгар-татар шәһәрләренең иң борынгысы булган Болгар шәһәренең 1100 елдан күбрәк булган тарихы турында сөйли. Соңрак Идел Болгарының башка шәһәрләре дә барлыкка килә: Ашлы, Казан, Алабуга, Юкатау, Нократ, Торцк (Торческ), Тухчин.

X гасырның беренче яртысында Болгар шәһәре мөселман дөньясы белән актив элемтәгә керә. Ул урта гасыр гарәп-фарсы әдәбиятында искә алына. 922 елда Багдад илчелеге секретаре булган ибн Фадланның «Рисалә» («Истәлекләр»), XII гасыр уртасы гарәп сәяхәтчесе әл Гарнатый китаплары, X гасыр гарәп классик география мәктәбе вәкилләре язмалары: әл Балхи, әл Масуди, әл Истахри, ибн Хаукалә, әл Мөкадәсси, XI гасыр гарәп тарихчысы әл Мәрвәзи хезмәтләре аеруча әһәмиятле булып торалар. Аларда Идел буе Болгар дәүләте һәм болгарлар, аларның шәһәрләре, тормыш рәвеше, Евразия илләре һәм милләтләре белән булган тышкы элемтәләр турында мәгълүматлар сакланган. Русь һәм Идел буе Болгар дәүләте үзара мөнәсәбәтләре турында бик күп кыйммәтле мәгълүмат рус елъязмаларында бар.





Урта гасыр язмаларында Бряхимов (1164 елда Лаврентьев елъязмасы), Болгар (рус елъязмалары һәм шәрык авторлары) һәм Бөек Болгар (1374 елгы рус елъязмаларындагы бердәнбер искәртү) шәһәре идел буе татарларының күп булмаган тарихи-археологик ядкәрләреннән дөньяга танылганнарыннан берсе булып тора. Татарстанның Спасс районында Кама тамагыннан 30 км һәм Иделдән 6 км ераклыкта (сусаклагычка кадәр)





*«Элек иске шәһәр булган,*
*Казанны матурлыгы белән каплаган,*
*Болгар – исламның изге өе,*
*Хәзер хәрабәгә әйләнгән.*
*Гаҗәп урында салынган,*
*Бөтен җирдән күзгә күренгән,*
*Горурлыгы – мәчетләре,*
*Хәзер хәрабәгә әйләнгән».*

*Гали Чокрый*



30 м биеклектәге төп идел террасасы читендә урнашкан харәбәләр күптән мөселманнарның хаҗ урынына әйләнде, берничә буын көнчыгыш өйрәнү белгечләре һәм археологлар Мәккәсенә әверелде.

XIII–XIV гасырларда ясалган шаһитләр бүгенге көнгә кадәр сакланган: Кечкенә манара, Кара, Ак, Кызыл пулатлар, Хан төрбәсе, Собор мәчете, таш мавзолей.



Болгарлар – күчеп йөрүче төрки кабиләләр атамасы, беренче тапкыр милләтләрнең Бөек Күчеш заманында латин «Хронограф» ында (354 ел) телгә алына. 630 елда болгарлар Кубрат хан җитәкчелегендә Бөек Болгар дәүләтенә нигез сала. Хәзәрләр белән барган озак сугышлардан соң халыкның бер өлеше Балкан ярымутравының төньягында беренче Болгар патшалыгын (681-1018






еллар) хасил итә, калган өлеше төньяк Европада төпләнә. Кайбер болгар кабиләләре (баранджарлар, барсиллар, биләрләр, савирлар һ.б.) Хазарстаннан Урта Иделгә күчә. IX гасыр азагында X гасыр башында болгарлар, үзләренә җирле фин-угор һәм төрки телле кабиләләрне буйсындыргач, Идел буе Болгар дәүләтенә нигез сала.

Болгар шәһәре X–XI гасырларда Көнчыгыш Европаның иң эре иртәфеодаль иленең башкаласы була. Соңрак, XIII – XIV гасырларда, шәһәр Алтын Урданың беренче башкаласы, Алтын Урда составында Болгар олысының (Джучи Олысы) мәркәзенә әверелә.

Сәүдә һәм стратегик яктан иң мөһим урында урнашкан Болгар шәһәре, Идел һәм Кама кушылган җир, баштан ук Идел буе милләтләре тормышында һәм бөтен Көнчыгыш Европа тарихында зур роль уйный.

922 елда болгарлар – хәзерге казан татарларының борынгы бабалары – рәсми рәвештә ислам динен кабул итәләр.



## Борынгы шәһәр мәдәнияты

Болгар Идел буе Болгар дәүләтен чолгап алган кабиләләр һәм милләтләр өчен көчле мәдәни, фәнни һәм техник йогынты ясаган мәркәз булган. Болгар һәм башка болгар шәһәрләре калдыклары белгән һөнәрчелек күнекмәләре бөтен Идел-Кама буена киң тарала. Хәзерге археологлар ачышлары Идел буе Болгар дәүләтенең мәдәнияты югары үсеш дәрәҗәсендә булганын раслый. Алтын һәм көмеш бизәкләр, таштан ясалган нәфис әйберләр милләтнең бай һәм эстетик культуралы булуы турында сөйли.

Борынгы дәүләтнең үзенең язмасы була. Керамика һәм зәркән әйберләрдә язылган бик күп язмалар грамоталылыкның киң таралуын исбатлый. Идел-болгар теле кабер ташъязмалары буенча билгеле.

Тарих киләчәк буыннарга соңрак «империя тел» ен барлыкка китергәндә Алтын Урда дәүләт башлыклары кулланган борынгы алфавит нигезләрен саклап кала.

Борынгы Болгарда бай базарлар һәм сәүдә сарайлары гына урнашмый, ә бәлки илһам хезмәтчеләре (музыка осталары, галимнәр, философлар һәм шагыйрьләр) дә үзләрен шәп хис итә.







Тарих безгә «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасын язган бөек шагыйрь Кол Галинең, галим һәм тарих белгече Якуб ибн Ногманның исемнәрен саклаган. Хөсәен әл-Болгарыйны замандашы «үз дәверенең бердәнбере, патшалар һәм солтаннар сөеклесе» кебек эпитетлар белән тасвирлый. Ул үзенең табиб мәктәбен оештыра һәм искиткеч яхшы дару препаратларын әзерләү һәм куллану методлары турындагы китабын бастырып (!) чыгара. Борынгы дөнья өчен чыннан да уникаль вакыйга. Борынгы дәвалаучының бик күп варислары һәм хөрмәт итүчеләре була, аның табиблык осталыгы шактый патша һәм күренекле шәхесләрне кыен хәлләрдән коткара. Хөсәен әл-Болгарыйның өйрәтмәләре аркасында борынгы Болгарның дәвалаучылары турында бөтен Шәрык дөньясы сөйли башлый. Безнең атаклы бабабызга



хәтта һәйкәл дә бар, ләкин ул ерак Әфганистанда урнашкан. Болгарларга багышланып ясалган Шишкин һәм Саврасов рәсемнәре билгеле. Бөек татар шагыйре М.Җәлил борынгы легенда мотивлары буенча поэма яза, ә композитор Н. Жиганов идел буе болгарларының татар-монгол золымына каршы көрәшен тасвирлаган «Алтын чәч» операсын иҗат итә. Хикәяләүдә болгарлык тарихы һәйкәле яңадан терелә.

Еш булган каршылыкларга карамастан, Болгар һәм Русь мөнәсәбәтләре һәрвакыт көчле була. Монголларга кадәрге шәһәрдә рус әйберләре, тормыш эзләре табылдылары билгеле. XII гасырда Идел буе Болгар дәүләте рус дипломатиясендә алдынгы рольне алып тора. Шул дәвер сәяхәтчеләре яза: » Болгар – гаять зур шәһәр... Ә аның тирәюнендә чиксез күп төрле милләтләр яши». Болгар мәдәниятында чыннан да «татулык чаты» шәһәре образы чагылыш тапкан, ул Шәрыкның иң яхшы традицияләрен үз эченә туплаган, аларны Көнбатыш йогынтысы белән яраштырган.

Болгар – ул Көнчыгыш Европаның Урта Азиягә булган сәүдә ишекләре. Аның аша көнбатышка төньяк халыкларның һөнәрчелек, аучылык продуктлары тапшырыла. Вакыт узу белән сәүдә үзәгендә һөнәрләр актив үсеш ала. Эшкәртелеше яхшы булган күн, анардан тегелгән итекләр («юфть» сүзе болгар теленнән алынган) шикелле, Хәлифатның бөтен базарында «болгарныкы» дип йөртелә. Хәзерге көнгә кадәр гарәп телендә югары төрдәге күн әл-Болгарый дип атала. Фәндә булган X–XI гасырлардан калган археологик



*«Болгар авылы. Кечкенә мәчет манарасы һәм Ак пулат хәрәбәләре». А. Саврасов, 1872-1874*



*«Болгар авылы».*
*А. Саврасов, 1872*

материаллар Болгар шәһәрен географик яктан уңайлы урнашкан урыны аркасында халыкара сәүдәгә кереп баручы ныгытмалы посёлок итеп күз алдына китерә.

XII гасырда Болгар, үзенең халыкара базар булуы әһәмиятен югалтмастан, башкала статусын Биләргә бирә. Монда шәһәрнең монголларга кадәрге чорда, идел юлы өчен көрәш сәбәпле, бер генә кабатланмаган җимерелүләре роль уйный. Шуңа да карамастан бу дәвердә шәһәрдә икътисад, һөнәрләр, сәүдә элемтәләре үсә, аның территориясе киңәя, яңа фортификацион юнәлеш төзелә. Шәһәрнең корылмалы өлеше 24 гектар тәшкил итә инде.

1236 елда борынгы башкала һавасы янгын аркасында каралана: Болгар монголлар тарафыннан кулга алына. Шәһәр бөтен дәүләт белән берлектә Джучидларга буйсынган олыслар системасына – Алтын Урда составына кертелә. Берничә елдан соң Бату хан Болгарны үзенең башкаласы итеп сайлый. Яңа күтәрелеш дәверендә, XIII гасыр уртасында, Болгар яңа дәүләтнең – монголлар тарафыннан барлыкка китерелгән империянең – көнбатыш чикләрендәге иң әһәмиятле шәһәренә әверелә.



XIII гасырда Болгар Алтын Урдада иң өстен рольне уйный. Болгар янында беренче Алтын Урда ханнары күченеп йөри. Монда XIII гасырның 60 еллары уртасында Бәркә-хан вакытында Собор мәчете төзелә (Джучи олысындагы мондый төрдәге беренче бина).

Болгар – 1250 елларда Бәркә дәверендә үк Алтын Урдада тәңкә чыгара башлаган беренче шәһәр. XIII гасырның 50 елларында Бату-ханга князьлек итү өчен ярлык сорап рус, әрмән һәм болгар князьләре килә. Менгу-Тимур, Бәркә-хан һәм Үзбәк дәверендә күп еллар Болгар Алтын Урданың икътисад, сәүдә, мәдәният һәм гыйбадәт кылу мәркәзләренең иң әһәмиятлесе була.

XIV гасырга кадәр, Алтын Урданың геополитик үзәкләре көньякка күчерелүгә карамастан, шәһәр империянең көчле мәдәни һәм сәүдә мәркәзе булып кала. Бу вакытта шәһәр бик нык үсә, ныгытылган өлеше 415 гектар җир били.

Болгарның Түбән Идел буе, Иран, Хәрәзем, Кавказ, Крым, Рус княжестволары белән сәүдә мөнәсәбәтләре үсә. Күп тармаклы һөнәрчелек эше чәчәк ата: XIV гасырда, Европадан 2 гасыр алдан (!), чуен коя башлыйлар. Уникаль архитектур корылмалар барлыкка килә: сарай бипалары, алпавыт утарлары, кәрван-сарайлар, собор һәм мәхәллә мәчетләре, мәктәп һәм мәдрәсәләр, җәмәгать мунчалары, мавзолейлар. Хәзер безнең замандашлар Төньяк һәм Көнчыгыш мавзолейлар, Кара, Ак, Кызыл һәм Көнчыгыш палаталар, Кечкенә манара, хан төрбәләренең күркәмлеген



*«Тарихы, үткәне белән кызыксынмаган, үзенең хәзергесен, киләчәген ярлыландыра. Үткән – ул бүгенгесен баетырга һәм киләчәген тәэмин итәргә теләгән һәркем аңларлык чиксез мәдәни хәзинә.*

*Хәтер юкка чыгаручы вакыт көченә каршы тора. Үткәнне белү – ул бүгенгене аңлау».*

*Д. Лихачев*





күз алдына китерә ала. Шәһәрне үстерүгә бик зур игътибар бирелә: күпер, сууткәргеч, дренаж системалары төзелә.

Урдада булган феодаль фетнә (Булат-Тимурның 1361 елда Болгарга булган походының бер эпизоды), елга юлбасарлары һәм XIV гасыр азагында XV гасыр башында рус князьләренең хәвеф-хәтәрле походлары, 1431 елда бөек князь Василий II тарафыннан җибәрелгән мәскәү воеводалары аркасында шәһәр җимерелүгә дучар була. Шул вакыттан Болгар сәяси аренадан төшеп кала, ләкин мөселманнар сәяхәтенең мәркәзе булып кала. Идел дәүләтенең башкаласы Казанга күчә.





Болгар җимерелүдән соң да рухи нигезен саклап кала: монда иһтирамлы мөселманнарны күмәләр, руханилар һәм дәрвишләр яши.

Урда гасырларда кайчандыр Болгарныкы булган җирләр Россия дәүләтенә кертелә. Патша Федор Алексеевич Болгар шәһәрлеге территориясендә булган борынгы таш биналарны тасвирларга әмер бирә. 1712 елда православия монастырена нигез салу өчен шәһәрлектә булган дьяк Андрей Михайлов 70 тән артык урта гасыр биналарын искә ала. Монастырь Болгарның үзәге булган Хан (князь) сарае даирәсе һәм Собор мәчете урынында салына. Император Петр I тарафыннан Русь буенча Себергә «физик яктан тасвирлау» өчен җибәрелгән Дания галиме Даниил Готлиб Мессершмидның 1719 елгы экспедициясе раслауларына караганда, Собор мәчете харәбәләре янында сакланып калган мавзолейларны («Дүртпочмакларны») монахлар үз кирәгенә җайлый: көнчыгыш мавзолей кечкенә храмга үзгәртелә – «Изге Николай чиркәве», төньягы – «Монастырь базы», хуҗалыкка ярақлаштырыла.

1722 елда шәһәрлектә Петр I үзе дә була. Ул борынгы шәһәрнең таш биналарын сакларга, кабер плиталары эпитафияләрен җыю һәм күчерү турында карар чыгара. Берничә елдан соң бай казан сәүдәгәре Михляев





тарафыннан монастырьга «Алиһәнең үлемен искә алу өчен» таш чиркәү төзетелә. Гыйбадәтханәне төзегәндә болгар харәбәләре ташлары, нигез өчен кабер плиталары кулланыла. Шулай Болгар шәһәрлегендә ислам һәм христиан диннәре тарихы бер арага килә.

1767 елгы Идел буенча сәяхәте вакытында Болгар ядкәрләре әби патша Екатерина II гә зур тәэсир ясый. Сәяхәт Тверьда башлана, әби патша анда Мәскәүдән килә һәм 2 меңлек яраннар белән ил гизүгә чыга. Яраннар арасында чит ил посоллары да була, алар аны Костромага кадәр озата. 10 карабтан торган флотилия белән Адмиралтейство

– коллегия президенты Чернышев җитәкчелек итә. Әби патша француз мәгърифәтчесе Вольтерга язган хатында:» Үземнең Идел буенча сәяхәтемдә мин борынгы Болгар харәбәләрен күрер өчен баркамнан төштем... Монда күп таш биналар һәм яхшы эшләнгән тугыз манара күрдем. Мин шушы харәбәләрнең берсе янына килдем, аның янында кырык татар намаз кыла иде. Губерна башлыгы миңа бу урынның татарлар тарафыннан изге саналуын әйтте: алар монда күпләп намаз укырга киләләр икән».

Монастырь, ул вакыттагы бик күп гыйбадәтханәләр кебек, XVIII гасыр азагында ябыла, Монастырь бистәсе Успенское авылы, соңрак – Булгар авылы дип йөртелә (Болгарның рус телендәге исеме варианты).

Монастырь шәһәрлеге территориясендә булган төзелеш һәм кайчандыр шәһәр булган җирлектә авыл барлыкка килү җимерелүләрне бары көчәйтә генә. Җирле халык борынгы биналарның ташларын хуҗалык эшләренә ташып бетерә, хәзинә эзләү белән





шөгыльләнә. Әгәр монда XVIII гасыр башында 70 бина булса, гасыр азагында нибары 44 кенә кала. Кайчандыр биналар, ә хәзер кызганыч ташлар гына күргән сәяхәтчеләр моны кайгырып тасвирлый. Шушылай Хан йорты, Грек палатасы һәм Әрмән зираты янында булган кәшәнә, Кара палата һәм Кечкенә манара арасындагы торак район, мавзолейлар комплексы юкка чыга. 1841 елда Собор мәчетенең Зур манарасы (Зур багана) ава. Авуның сәбәпе булып аның нигезендә хәзинә эзләүчеләр ярдәме белән барлыкка килгән бушлыклар тора. Мәгърифәтле гасыр азагында Ак палата җимерелә.



*«Болгар – христианнар һәм мөселманнар яшәгән шәһәр исеме, соңгылары зур мәчет иясе. Мәчетне шәһәрдә торучы халык кышка күчә торган олы агач өйләр белән урап алган, ә җәен алар чатырда һәм җиңел агач өйләрдә яшиләр».*

*Әл-Идриси*



Шуңа да карамастан, Болгар бик күп гасырлар борынгы шәһәр хәрабәләренең тасвирламаларын, сызымнарын, планнарын һәм рәсемнәрен калдырган тарихчылар һәм сәяхәтчеләр, язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, гаскәр башлыклары, архитекторлар, рәссамнар, өлкәне өйрәнүчеләр өчен юл күрсәтүче йолдыз булып тора.

1864 елда Хатыннар калкулыгында казу эшләре алып барылганда Болгар территориясендә В.Г. Тизенгаузен җитәкчелегендә археологик тикшеренүләр башлана. 1877 елдагы археологик съезд борынгы Болгарның ядкәрләренә дәвамлы озак күзәтү кирәклеген билгеләде, Казан университеты нигезендә археология, тарих һәм этнография оешмасы барлыкка китерелә. 1962 елда Болгар авылында тарихи-архитектур музей, соңрак Болгар тарихи-архитектур заповеднигы ачыла (Болгар тарихи-архитектур музей-заповеднигы).













# ХАН САРАЕ

Галимнәр Болгарда хан сараен йөз елдан артык эзлиләр; аның урнашу урыны бик кызыклы һәм бәхәсле предмет булып тора. Археологлар тарафыннан табылган ядкәр 1997 елда Татарстан Фәннәр академиясе Тарих институты тарафыннан тикшерелә башлый. Бүгенге көндә 1300 кв.м.дан артык булган мәйдан ачылган.

Монда чыннан да күләме белән бик зур таш бина табыла, ул беренче таш салу дәрәҗәсенә кадәр сакланып кала.

Ниһаять, 2010 елда эзләнүләр барышында аның Бату-хан (1208-1255) – Алтын Урда хөкемдары (1227 елдан), Джучи улы һәм Чыңгызхан оныгы – сарай комплексына кергәнлеге турында бәхәссез дәлилләр ясала.

Моңа комплексның архитектура үзенчәлеге һәм бик күп табылдыклар ишарә ясый. Сарайның таш монументаль бинасы Урта Азия, Иран, Индиядагы шушындый комплекслар сарай ансамблен хәтерләтә. Монда кулланылган әйберләр табыла, шул исәптән XIII гасыр уртасында Бату-хан суккан монеталар да.

# Бүген Борынгы Болгарны саклап калу ни өчен мөһим?

X – XV гасырларда архитектура һәм мәдәният үсешенә зур йогынты ясаган тарихи-археологик комплекс урта гасыр дәүләтләре (Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда), мәдәнияты, тормыш тәртибе турында сөйләүче дөньяда аналогы булмаган кыйммәтле тарихи ядкәр.

Комплексның архитектура ядкәрләре төньякта урнашкан урта гасыр мөселман төзелеш сәнгатенең иң ерак объектлары, XIII – XIV гасырлар уртасындагы болгар-татар архитектурасының уникаль һәм бердәнбер үрнәге булып санала.

Болгар тарихи-археологик комплексы территориясе үткәннең археологик дәлиле, безнең ораның беренче меңьеллыгы уртасыннан кешенең биредә булуын күрсәтүче, төзелеш



төренең искиткеч мисалы, архитектура һәм ландшафт ансамбле, кешелек тарихының берничә дәверен тасвирлаучы, кешеләрне урнаштыру һәм территориягә халык утырту үрнәге булып тора. Иң иртә ядкәрләр мезолит дәверенә карый. Ага-базар аймагы һәм Дала күле булган районда неолит һәм бакыр дәвере ядкәрләр сериясе теркәлә. Табылдыкларның күбесе иң беренче тимер дәверенә карый. Болгар комплексы территориясендә төрле вакытта элекке рим монеталары табыла.

Нәкъ Борынгы Болгар 922 елда Идел буе болгарлары – Казан татарларының борынгы бабалары – тарафыннан рәсми рәвештә ислам кабул ителгән урын була.

Ул гыйбадәт кылу, мөселманнарның изге хаҗ мәркәзе.

Болгар – Алтын Урданың беренче башкаласы һәм 1250 елларда Бәркә-хан вакытында беренче Алтын Урда монеталары койган урын.

Борынгы шәһәр – Россия империясендә тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне бозмау һәм саклау проблемасы искә алынган беренче урыннарның берсе. Моның дәлиле – 1722 елның 2 (15) июлендә язылган Болгарлар турындагы император Петр I указы – безнең илдәге күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкәрләрен саклау турындагы беренче документ.





ЕЛГА ВОКЗАЛЫ-МУЗЕЕ
ОПЕРАЦИОН ЗАЛЫ



МУЗЕЙ ВАЗЫЙФАСЫН
ҮТӘҮЧЕ ЕЛГА ВОКЗАЛЫ

2010 елда «Яңарыш» фонды көче белән борынгы Болгарда реконструкция һәм реставрация буенча масштаблы эшләр башланды, яңа туристик һәм сәяхәт мәйданнары ясала. Шулар белән беррәттән Казан археологларының күпьеллык эшләре дәвам итә. Галимнәр борынгы цивилизация турында сөйләүче күпсанлы табылдылар белән таң кала.










Мәһабәт Болгар иң якын вакытта үзгәреп китәчәк. Идел буенча сәяхәт итүчеләрне, заманча техника белән баетылган, болгар осталары стилендә эшләнгән, елга вокзалы каршы алачак. Акваториядәге иң зур комплекс музейлар, сәүдә павильоннары, күзәтү площадкалары һәм күңел ачу террасаларын үз эченә алачак.

Мөселман сәяхәтчеләре өчен аерым парковкалы, гади, ләкин җайлы сервислы күпмеңлек чатырлы шәһәрчек төзү каралган. Борынгы Болгарда иманга ирешү хөрмәтенә багышланып ясалган истәлекле ишарә мөселман дөньясы өчен мөһим роль уйнаячак. Мөселманнар тарихы гасырлар дәвамында мәһабәт храм комплексында сакланып калачак.

Монда, Болгарда, яшь буын вәкилләре, 2013 елгы универсиада катнашучыларын кунак итеп, аларны туган ил тарихы белән таныштыра алачак.


ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮ ХӨРМӘТЕНӘ БАГЫШЛАНЫП ЯСАЛГАН ИСТӘЛЕКЛЕ ИШАРӘ







# Свияжск утрау-шәһәре



*«Бөек князь агачлы стеналарны, башняларны, капкаларны, балкаларны һәм бурәнәләрне астын өскә китерергә әмер бирде. Соңыннан бу шәһәрне җимерделәр. Салларга салына һәм хәрби кешеләр белән Идел буенча аска таба агызыла. Шәһәр рус кешеләре һәм артиллерия белән тулган. Аны Свияжск дип атыйлар».*

*Генрих фон Штаден «Мәскәү турында хатлар»*



*Җил күңелле шаулый,*
*Караб күңелле йөгерә*
*Буян утравы буеннан,*
*Салтан җирлегенә.*
*Теләгән дәүләт,*
*Менә инде ерактан да күренә.*

*А.С.Пушкин*



Замандашлары әйтә: Александр Пушкин Свияжск шәһәрен күреп хәйран кала (ә бу хәл «Солтан турындагы әкият»не язгач була) һәм юлдашларына могҗизалы шәһәрне нәкъ шулай күз алдына китерүен әйтә. Еллар үтә һәм Свияжск күбрәк әкияти утрауны хәтерләтә, хәзер инде тулысынча су белән уратып алынган. Ул үзенчәлекле тарту көченә ия, монда кире әйләнеп кайтасы, үткәнгә кагылып карыйсы, киләчәк турында уйлыйсы килә.



Пушкин «андыйны тапмаслык бу ак дөньяда» дип хаклы булган. Утрауда, вакыт һәм киңлекне җимереп, күнеккән әйберләргә караш үзгәрә. Һәм «вакытлыча үзгәреш» – бу шәһәрдә гадәти хәл: исемнәрне саклаган урамнар, таушалган чиләкләрдә коедан су ташучы һәм шул ук вакытта «мобильниктан» тиз генә нәрсәдер сөйләшүче картлар. Теләсә кемгә бар, сора – шәһәр тарихын сөйләячәкләр. Утраулылар үз тарихын бик яраталар.

Бүгенге көндә утрауда үзенчәлекле кешеләр яши. Соңгы елларда күбесен Свято-Успенский монастырен яңадан тудыру идеясы берләштерде. Православие халкы утрауга ашкынды, кулдан килгәнне ярдәм итәргә тырышты.



*«Торгызылган тарихи Болгар һәм Свияжск истәлекләре кеше кызыксынуын һәрвакытта җәлеп итәргә тиеш ... Безнең уртак һәм мәрхәмәтле эшебез киләчәк буыныбыз белән бәяләнер. Ышанам, без алынгач, уңышка ирешербез. Без булдырабыз!»*

*М.Шәймиев*

Монастырьда яшәүчеләр, аларга кадәр булганнарның традицияләрен исәпкә алып, утрау халкында һәм сәяхәтчеләр йөрәгендә тирән, көчле иман уяталар.

Утрау халкының бик күп өлеше – иҗат интеллигенциясе. Утрауның матур җирләре фотографларны, художникларны, шагыйрьләрне һәм музыкантларны хисләндерә. Ләкин юлчыларны һәм заман илһам хезмәтчеләрен утрауның матур җирләре генә сокландырмый.

Свияжскида табигать һәм искелекнең үзенчәлекле матурлык дөньясы сакланган, юкка гына аны православие утравы мәдәнияты дип атамаганнар. Кайчандыр Свияжскидан 2 юл чыккан: берсе Казанга, икенчесе



Мәскәүгә. Һәм утрау өчен бу символик әһәмияткә ия. Монда Россия һәм Казан легендалары, риваять һәм хикәятьләре берләшә.

XVI гасыр уртасында нигез салынган шәһәр Россия дәүләтен формалаштыру процессында төп рольне уйнарга тиеш була.

Свияжск чын мәгънәсендә Евразия континентында барган геополитик үзгәрешләрнең көньяк плацдармына, яшь Россия империясенең форпостына әверелә.

Бүгенге көндә кечкенә җирдә (утрауны 1 сәгать эчендә әйләнеп чыгып була) 26 федераль архитектура истәлекләре урнаштырылган. Аларның бөтенесе – борынгы рус хрестьян төзелеш сәнгате хәзинәләре.

Зурлыгы һәм ныклыгы буенча крепость ни Новгород, ни Мәскәү кремльләренә) юл бирми: диварлар 2,5



метрдан 5 метрга кадәр, 7 капка, 18 каравыл манарасы, 3 җир асты юлы – елга ярына төшү юлы. Ышанып булмый, ләкин шәһәр 4 атна эчендә төзелде.

XVI гасыр уртасында Свияжск төзелешенә бер төркем кеше, Псков мастерлары Постник Яковлев һәм аның ярдәмчесе Иван Ширя килә. Мәшһүр архитекторлар соборларны Казандагы мәһабәт кафедраль Благовещенск соборын һәм республика горурлыгын – Казан Кремленең ак диварларын төзегәч сала башлыйлар.

Киләсе йөзьелларда утрау Идел буеның иң эре мәдәни һәм православие мәркәзе булып саналган, юкка гына патшалар, рәссамнар һәм шагыйрьләр анда килмәгән.

Бушау һәм онытылу елларына карамастан, ә бәлки алар ярдәмендә, шәһәр замана рухын саклап кала. Свияжскиның иң беренче



«Казанны басып алганнан соң хан территориясе 2 уездга аерыла – Казан (Волганың сулъяры) һәм Свияжск (уңъяры), алар Казан ханлыгының приказлары белән идарә ителәләр. Ханлыкның юкка чыгуы белән Свияжск үзенең терәк базалы мөһимлеген югалта һәм кушылган территориядә колонияләү һәм христианлаштыру форпосты була. XVII гасырның уртасында, хәрби катламның таратылган линиягә һәм Әстерханга күчерелүе белән, Свияжск халкы кинәт азая, ә XVIII гасыр башында, тузган булу сәбәпле, ныгытмаларның калдыклары җыела».

агач төзелеше – урта гасыр Троицк чиркәве. Вакытлар үтү белән Свияжскиның күп кенә агач храмнары «таш» киемнәр киделәр, ә крепость диварлары бернинди үзгәреш кичермичә үзенең «агач» гасырын үткәрә. Соңгы тапкыр алар 1703 елда Персия юлы буенча голланд рәссамы Корнелий де Бруин шәһәрне карап үткәндә искә алына. Свияжскиның иң иртә сурәтләре дә аңа карый. Голланд үзенең язмаларында «шәһәр тауда ята һәм Кремле бар» дип билгеләгән. Аңарда бик күп таш чиркәүләр һәм монастырьлар, ләкин стеналары һәм өйләре агач». Корнелий де Бруин үз рәсемен 1711 елда Амстердамда бастырып чыгара.

Якынча шушы елларда Свияжскида үз гербын булдыра, һәм кызык, инде шул вакытларда анда төп үзенчәлек – зур көймәдә йөзеп баручы шәһәр образы – чагылыш таба.

Свияжскида, бернинди арттырусыз, һәрбер таш тарих белән сулый. Әгәр дә сез ялгыш кына кечкенә агач казыкка юлыксагыз, яхшылап карагыз – бәлки ул XVI гасырдан килгәндер.











*Беренче рухани хөҗрәләре – беренче монастырь башлыгы Герман атаның Свияжскига сәяхәтенең иң төп объекты була, могҗизалы терелүләр монда сирәк булмый.*

Утрауда үз теләкләреннән башка яшәүчеләр, куркыныч елларда монастырь территориясендә урнаштырылган концлагерь тоткыннары, монах бүлмәсеннән фәрештә тавышлары килүне һәм тыныч, җылы утның януын искә алалар. Бәлкем монах җаны таркатылган монастырь һәм аның тоткыннарына дога кылгандыр...

Бик озак еллар монда кайгы белән искә алына торган Себер трактының дүрт сөргеннең бер пункты була, риваятьләргә караганда, шуны ук соңгы Казан патшабикәсе Сөембикә үз җилкәсендә татый. Герцен, Радищев кебек декабристлар Свияжскиның ихтыярсыз кунаклары булалар...



*Свияжскида урнашкан Иоанно-Предтеченск хатын-кызлар монастыренең үсеш югарылыгы булып Изге Ана иконасына багышланып ясалган «Шатлыкны искә алучылар» мәһабәт соборы тора. Дивеевода булган шикелле, монда бу үлемнән алдагы үсеш була. Собор рус-византия стилендә эшләнгән һәм ул Свияжскидагы югарылыгы буенча Успенский чиркәү манарасыннан (43м) соң икенче урында торган корылма.*

*Төп купол – ярым сфера, византиянеке, 16 тәрәзәле бөҗралы, үзенең конструкциясе һәм планировкасы белән Константинопольдагы Изге София храмы тышкы күренешенә охшаган.*

*Бөлгән пасхалы-кызыл собор – Казанның мәшһүр архитекторы Малиновский иҗаты – шушында ук күмелгән храм хуҗасы Калиста ананың соңгы төзелеше. Искитәрлек тәңгәллек – күрше Сергиевск чиркәве үз вакытында – бөек Смута алдыннан XVII гасыр башында – хәлакәт елында төзелгән. Саваоф алла образы һаман да храмның эченә керүчеләргә явыз моңсулык белән 30 метр биеклектән зур куполдан карап тора. Шушы ук куполдан һәм түгәрәкләнгән гөмбәздән теләсә кайсы тавышның кайтавазы бушлыкта кабат яңгырый: соборның акустикасы, Ф. Малиновскийның бөтен соборлары шикелле, искитәрлек...*





# Ни өчен Свияжскны сакларга һәм торгызырга кирәк?

Утрау-шәһәренең уникальлеге – борынгы рус агачтан шәһәр төзү сәнгатенең берьюлы агач биналар һәм корылмалар нигезен салу масштабы буенча бердәнбер мисалында (Мәскәү астындагы Углич урманнарында алдан әзерләнгәннәреннән, Свияжсктан 800км ераклыкта урнашкан). Елъязмаларга караганда, 75 мең кеше ныгытманы 24 көн төзегәннәр. Мондый темпларның борынгыда тиңдәше булмаган.

Утрауда һөҗүмгә каршы тора алырлык, иҗтимагый, табынырдай, яшәү һәм хуҗалык өчен файдаланырлык (кремль диварлары һәм кечкенә шәһәр ныгытмалары, сууткәрү һәм канализация системалары, борынгы юллар, элекке йортлар, мәхәллә һәм монастырь чиркәүләре), XVI гасыр уртасы рус халкы мәдәниятының матди һәм рухи материалларының, агач һәм таш биналарның калдыклары сакланган.

Тарихи Свияжск шәһәренең мәдәни катламы XVI гасырның рухи, иҗтимагый, сәнгать, технология һәм фәнни ирешүләренең объектив мәгълүмат чыганагы була.

Мәдәни катламның аңлаешлылыгы төзелешнең түбән тыгызлыгына, ландшафтның саклануына һәм Свияжскиның элекке посад өлешендә булган туфракның үзенчәлегенә карамастан, Свияжск замана археологиясе күзлегеннән дә кабатланмас.

Свияжск Успенский соборы фрескалары (1080 кв.м.) – алар язу рәвеше һәм төс колориты буенча борынгы рус фреска мәктәпләренең берсендә дә аналогы булмаган, Иван Грозный заманыннан безнең көннәргә килеп җиткән бердәнбер стена рәсем сәнгате ансамбле һәм XVI гасыр уртасыннан иң яхшы сакланган тирән эчтәлекле язмаларның циклы.

Тарихның бәя биреп бетергесез бүләкләре белән реставраторлар эшләделәр инде. XVII гасырда аш табыны өлеше төзелә, ә тагын бер гасырдан соң гөмбәз корыла, уникe бизәкле кокошниклар гыйбадәтханәне тәгәлли. Успенский соборның «челтәрле» шәүләсе Свияжскиның XVIII гасыр гравюраларына төшерелгән. Ләкин бу эшләрнең дәвам ителүе кирәк...







*«Успенский Собор дивар рәсеме якынча 1561 ел белән билгеләнгән. Авторы билгесез. XVI гасыр ядкәрләренең начар саклanulары сәбәпле Успенский собор фрескаларына аналогияләр табу авыр, бу исә шушы искиткеч әсәрне борынгы рус сәнгате раритетлары сафына кертә».*

*Сәнгать белеме галиме В.Немтинова*





Казан тарихчысы А.Рощектаев храм турында болай яза: «Собор алтарь ягыннан ифрат матур. Аның күренекле ярымтүгәрәк апсидларына Новгород яки Псков борынгы храмнарының теләсә кайсы кызыгыр иде. Көчле ярымтүгәрәкләрнең кушылуы, алардагы новгород-псковның бәйрәмдәгедәй җиңел йөзлекләр белән гадәти уеп ясалган бизәге искитәрлек таләпчәнлек һәм матурлык килешлелеген барлыкка китерә.

Көньяк һәм төньяктан булган ачык төркем – халык күңел ачу урыны – чиркәүгә купшы һәм серле кыяфәт өсти. Рус төзелеш сәнгатенең Петр I кадәрге дәверендә гыйбадәтханәләрне төркемнәр белән әйләндереп алу бик киң таралган була. Алар үзләренә бер төрле борынгы атмосфераны саклыйлар. Чынлап та, соборны болай итеп кыйммәтле тышлау зур хәзинә булып санала.







Россиянең XVI-XVIII гасырлардагы сынлы сәнгатенең иң яхшы яклары үзенчәлекле катламнар белән стихияле рәвештә изге Германга багышланып ясалган чиркәү-һәйкәл тышкы күренешендә чагылыш тапкан».

Изге Успенский соборының алтын йөгертелгән тәресе – XVIII гасырның күп булмаган кисеп ясалган тәреләренең берсе. Ләкин чын мәгънәдәге могҗиза – фрескалар; әсир итәләр, кояш нурларында тутыкмастан җемелдиләр, алтын һәм ал, зөбәрҗәт һәм күктәй зәңгәрсу «таш» төсләр (борынгы рәссамнар төсләрне махсус



төрләрдән «ышкып чыгаралар»). Галимнәр белә: ул дәвернең дивар сәнгатенең тулаем циклы аеруча сирәк. Свияжск дивар рәсемнәре Россиядән ерак җирләрдә соклану хисе уята.

Свияжск – бердәнбер тарихи-мәдәният ядкәре, бөтен Россия халкының горурлыгы,дүрт ярым йөзьеллык аша безгә гомуммәдәният хәзинәсен тапшыра алучы. Заманча эшләнгән утрау-шәһәрнең берничә тарихи-мәдәният катламы бар, алар Иван Явыз кадәр үк барлыкка киләләр.



Свияга елгасы үзе – хәтта беренче кешеләрнең тукталышлары да сакланган бердәнбер күренеш. Свияга елгасының башы Ульяновск өлкәсе территориясендә иканлегән бөтенесе дә белми, ул Идел агымының аска таба булган агымында урнашкан, Свияжск утравы янында Иделгә коя, ә ул исә су агымы буенча өскә таба урнашкан. Туристлар өчен табигать сере түгелмени?

Свияжск урамнарын һәм мәйданнарын үткәндә, үзеңне гадәти өлкә шәһәре эскәмияләре, йортлары кунагы дип күзалдына китерергә була. Свияжск утравын чын мәгънәдә Идел буе мәрҗәне дип атарга була.

Свияжск кайчандыр Түгәрәк тауның өстен били, хәзерге вакытта кечкенә генә, озынча түгәрәк булган, әз генә көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка таба сузылган (аркылыга якынча 900 метр ) утраuга әверелә. Чиркәүләрнең башлары судан ук күренеп тора, утрау кечкенә генә һәм аз катлы булганлыктан, анда адашырга мөмкин түгел. Совет заманында Свияжск, зур булмаган авыл, урам исемнәрен алыштыруны читләтеп үткән, монда да тарихи исемнәр сакланган. Төп урам – Успенск, шәһәрне төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба кисеп үтә, аңа параллель рәвештә Троицкая (көньяктарак) һәм Никольская (төньяктарак) урамнары сузыла, ә утрауның нәкъ уртасында аларга перпендикуляр рәвештә Александровская урамы үтә.







Свияжскиның иң төп истәлекле урыннары — аның монастырьлары: ир-атларның Успенско-Богородицкий һәм хатын-кызларның Иоанно-Предтеченский (хәзерге вакытта ир-атлар монастыренә берләштерелгән). Икесе дә утрауның көнбатышында урнашкан һәм, караблар шәһәр янына Казан ягыннан якынлашканда, судан да яхшы күренәләр.

Свияжск күренекле Россия һәм бөтендөнья тарихы шәхесләрен кабул итү җире булды: Явыз Иван патша, Сөембикә-ханбикә, изге Герман Свияжски (1595 елда куәт туплаганлыктан Герман изгеләр рәтенә кертелгән), Екатерина II әби патша, император Павел I, Александр I һәм Николай I, Г.Р.Державин, А.С.Пушкин, Ф.И.Достоевский, Л.Н.Толстой һәм башкалар.



Шәһәр булган Свияжскиның шәһәр төзелеш ансамбле аны XVI гасырның иң зур шәһәрныгытмалы хәзинәсе итеп күз алдына китереп бастыра. Утрау комплексы үзенең зурлыгын, формасын, шәһәр төзүнең башлангыч идеясе нигезләрен, планлаштыру кысаларының бердәмлеген, күләмкиңлек композициясен һәм комплексларның функциональ оештырылуын саклап кала. Беренче шәһәр төзелешләре саклану да бик уникаль – агач Троицк чиркәве (1551ел), Никольская чиркәве (1556) һәм Успенск соборы (1660). Региональ шәһәр төзелешләре һәм архитектур традицияләренә бирелмәве дә сокландыра.

Свияжск Свято-Успенск ир-атлар монастыре турында аерым әйтәсе килә. Казан епархиясендәге һәрбер монастырьның – Аллаһ тарафыннан һәм тарих ягыннан билгеләнгән үз йөзе һәм











үз вазифасы. Ләкин «вакыт ачкычлары» Свияжск монастырендә саклана. Чөнки иманлы кешеләрнең үтә изге нәрсәләрен саклавы аркасында хәзерге кешеләр гасырлар тирәнлегенә карый ала.

Һәм бүген, бик күп гасырлар элек булган кебек, Никольский храмының кырык метрлы дүрт ярусды чиркәү манарасыннан елганың үзәккә үтә торган тыныч тормышына карап сокланырга мөмкин...



*«Бүгенге Болгар һәм Свияжск – бу үткән вакытның тере дәлиле. Күпне монда төзекләндерергә, халыкка нормаль мөмкинлекләр тудырырга, һәйкәлләрне реставрацияләргә, аларны бүгенге көндә күбәеп баручы туристларга җайлаштырырга кирәк. Бөтен дөньяда шулай эшлиләр».*

*М.Шәймиев*









*«Монда эшләнәчәк һәр эш сыйфатлы эшләнәчәк... Мин ышанам, бу урын бөтен Россиягә, бөтен дөньяга билгеле булачак, һәм монда тарихка, мәдәнияткә, рухи байлыкка кагылып карар өчен киләчәкләр».*

*М.Шәймиев*

Гомумән, күпъеллык кызыклы утрау тарихы – дәүләт тарихында булган хакимият һәм халыкның ата-бабалар йолаларына булган мөнәсәбәтенең чын дәлиле.

Утрауда «Яңарыш» фонды барлыкка килү – замананың ишарәле символы. Бүген фонд тарихи раритетларны һәм борынгы шәһәрнең мәдәни мирасын саклап калу өчен бөтен тырышлыгын куя.








ЕЛГА ВОКЗАЛЫНЫҢ ТӨП ФАСАДЫ



2010 елның җәендә «Яңарыш» фонды ярдәмендә Свияжскида зур үзгәрешләр вакыты башланды. Әкияти утрау икенчегә туу вакытын кичерә. «Бөтен фронт» буенча да төзелеш башланды. Свияга яр буенда дамба юыла, пристань төзелә, вокзал буе мәйданы һәм елга вокзалы бинасы төзелә. Монастырь храмнарында



реставрация эшләре алып барыла.

Төзүчеләр белән бергә утрауда галимнәр дә эшли – актив археологик эзләнүләр алып барыла.

Тиздән утрау-шәһәргә туристлар һәм православия хаҗилары зур агым булып киләчәк. Свияжск Идел буеның иң зур мәдәни-тарихи мәркәзенә әвереләчәк.





Утрауда вакыт белән җимерелгән тарихи һәм архетиктур ядкәрләрне тиз арада һәм уйламыйча гына торгызу булмаячак. Реставраторларның төп девизы: искелекнең кадерен саклап калу...

Юлчылар өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылачак: аларны заманча пристань һәм кунакханә каршы алачак, арбалы атлар борынгы урамнар буенча экскурсия тәгъдим итәчәк.




АТЛАР САРАЕНЫҢ ТӨП ФАСАДЫ



Фонд программасында шулай ук утрау халкының кискен торган иҗтимагый һәм торак шартлары проблемаларын чишү дә каралган. Чөнки җирле халык – рәссамнар, балыкчылар, руханилар – бары йолалар, мәдәният һәм тарихның чын вәкилләре генә түгел, шулай ук Татарстанның гражданнары да.



ИШЕГАЛДЫ

«Яңарыш» фонды

“ЯҢАРЫШ” ФОНДЫ
«КОММЕРЦИЯ ОЕШМАСЫ БУЛМАГАН «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИХ
ҺӘМ МӘДӘНИЯТЫ ЯДКӘРЛӘРЕН ТОРГЫЗУ ФОНДЫ» ТҮЛӘҮ РЕКВИЗИТЛАРЫ

1. Республиканың “Яңарыш” фонды
ИНН 1655069125 КПП 165501001
Түләү счеты 40703810600000000153 ЗАО «Татсоцбанк» та
БИК 049205703 Корр. счет 30101810500000000703
Түләүнең максаты: ирекле хәйрия түләве

2. Татарстан Республикасының тарих һәм мәдәнияты ядкәрләрен торгызу фонды
Саклау счеты № 40603810200020000245
ОАО «АК БАРС» БАНКта
Корр. счет № 30101810000000000805
БИК 049205805
КПП 165501001
ИНН 1655069125
Түләүнең максаты: ирекле хәйрия түләве

Контактлар өчен белешмәләр:
420111, Казан, Чернышевский урамы 18 /23
тел. (843) 2922027, 2922551

# ТАТАРСТАННЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ

Фәнни консультант
“Казан Кремле” дәүләт тарихи-мәдәни һәм сәнгать тыюлык музее директоры,
тарих фәннәре кандидаты **Рамил Хайрутдинов**

Махсус фотосъемка: **Михаил Козловский, Альберт Тахавиев**
Чыгарылыш өчен җаваплы: **Максим Андреев**
Редактор: **Юлия Андреева**
Макет дизайны: **Александр Деревенсков**

Китапта ГУП «Татинвестгражданпроект» тәкъдим иткән проектлар,
Болгар дәүләт тарихи-архитектур тыюлык музее директоры Рафаэль Мәхмүтов фото эшләре,
Свияжск Богородице-Успенск монастыренең һәм «Заман» нәшрияты архивы материаллары кулланылды



Басмага кул куелды 07.10.2010. Формат 64x90 1/8.
Ак буяулы кәгазь «Galerie art». Офсет басма.
Гарнитура «Myriad Pro». Битләрнең басылу шарты 8,6
Тираж 500 данә. Заказ 07-10/04-1

НӘШРИЯТ ЙОРТЫ

420108, Казан шәһәре, Портовая урамы, 25а.
Тел./факс: (843) 231-05-46, 231-05-61, e-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru